## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Рангазар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

2025 елның 26 ноябре № 1

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы "Дәүләт хакимиятенең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 45, 69 маддәләренә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Законының 35 маддәсенә нигезләнеп, 2025 елның 26 ноябрендә узган гражданнар җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Рангазар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы сез, I группа инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, вакытлы хәрби хезмәт узучы гражданнардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучылардан, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылардан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы:

1) Рангазар авыл зираты территориясен киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2) Беларус тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

3) Рангазар авылында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) ;

4) Рангазар авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

5) Рангазар торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

6) Рангазар авылында Сабантуй территориясен төзекләндерү;

7) Рангазар торак пунктында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (транспорт хезмәтләре күрсәтү, эшләр өчен шартнамә буенча түләү)

ЭЙЕ ЮК ?"

мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә йомгаклау беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 224 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 132.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышы түбәндәгечә бүленде: «хуплау» позициясе өчен гражданнар Җыенының 132 катнашучысы тавыш бирде; «каршы» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең Рангазар торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Рангазар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, вакытлы хәрби хезмәт узучы

гражданнардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучылардан, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылардан тыш 2026 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Рангазар авыл зираты территориясен киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2) Беларус тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

3) Рангазар авылында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) ;

4) Рангазар авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

5) Рангазар торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) ;

6) Рангазар авылында Сабантуй территориясен төзекләндерү;

7) Рангазар торак пунктында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (транспорт хезмәтләре күрсәтү, эшләр өчен шартнамә буенча түләү)

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Рангазар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге башлыгы Р.Н.Кыямов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ОГРН 1021601313470
Совет Рангазарского сельского поселения
Рангазар авыл җирлеге Советы
ИНН 1636001280